ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге хакында (Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында еллык хисапны тәкъдим итүгә бәйле рәвештә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы куйган мәсьәләләр буенча, еллык хисапны тәкъдим итү хакындагы $190^2$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән мәсьәләләр исемлеген Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрергә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 феврале
№ 2322-VI ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2024 елның 6 февралендәге 2322-VI ДС номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге**

*Икътисад, бюджет*

1. Татарстан Республикасы сәнәгатенең машиналар төзү тармагында һәм аграр комплексында цифрлаштыру торышы турында.
2. Татарстан Республикасында технологияле техник чаралар булдыру, җитештерүне автоматлаштыру, роботлаштыру, интеллектуальләштерү максатларында цифрлы технологияләрне гамәлгә кертү хакында.
3. Татарстан Республикасында энергетика тармагының торышы һәм аны модернизацияләү перспективалары хакында.
4. Республика икътисадында кадрлар кытлыгы арта баруга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелә торган чаралар турында.
5. Импортны алмаштыру нәтиҗәләре хакында һәм аларның республика икътисадына тәэсире турында.
6. Татарстан Республикасының «Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимнарын билгеләү буенча экспериментларда катнашу йомгаклары хакында.
7. 2024 елда Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын үткәрү планында каралган чараларны гамәлгә ашыру барышы турында.
8. Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык тармагында мәгълүмати технологияләрне киңәйтү перспективалары хакында.
9. Пространстволы планлаштыру институтын төзүгә бәйле рәвештә «Стратегия – 2030»да каралган агломерацияләрне (Казан, Кама, Әлмәт) үстерү өчен күрелә торган чаралар турында.
10. Бүгенге шартларда республиканың тармак ресурс үзәкләре эше, аларның укыту-методик базасын модернизацияләү һәм аларны югары технологияле җиһаз белән тәэмин итү хакында.

*Социаль сәясәт*

11. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларының хокукларын, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучының булу урыны һәм аның статусы (яралы, һәлак булган, хәбәрсез югалган) турында үз вакытында дөрес мәгълүмат алу хокукын, гамәлгә ашыру өлешендә күрелә торган чаралар хакында.

12. Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча үткәрелә торган эш турында.

13. Чит ил студентларын һәм мигрантларның балаларын иҗтимагый мохиткә социаль һәм мәдәни интеграцияләү максатларында үткәрелә торган эш хакында.

14. Татарстан Республикасында яшьләрнең һөнәри куәтен, хезмәт һәм эшкуарлык куәтен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру турында.

15. Авыл җирендә яшь квалификацияле кадрлар кытлыгын бетерү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте планлаштыра торган чаралар хакында.

16. Сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәләрендә кадрлар кытлыгын бетерү чаралары турында.

17. Опекуннарга һәм попечительләргә Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясында билгеләнгән түләү күләмен арттыруның максатка ярашлылыгы хакында.

18. Гаилә кыйммәтләрен һәм аңлы рәвештә ата-ана булуны формалаштыру эше турында.

19. Татарстан Республикасында балаларның җәйге ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне әзерләү һәм оештыру хакында.

20. Мобилизацияләнгән гражданнар гаиләләренә ярдәм чараларын оештыру турында.

21. Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру хакында.

22. Эшчәнлеге Татарстан Республикасында ана булу мәсьәләләренә, балачак һәм хатын-кыз хокуклары мәсьәләләренә бәйле булган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга дәүләт ярдәме турында.

23. Республиканың зур шәһәрләрендәге яңа микрорайоннар территорияләрендә яңа сәламәтлек саклау, мәдәният, мәгариф учреждениеләрен төзү (ачу) перспективалары хакында.

*Сәламәтлек саклау*

24. Татарстан Республикасында онкология авыруларын иртә ачыклау һәм профилактикалау, мондый учреждениеләрнең матди-техник базасын киңәйтү һәм ныгыту буенча үткәрелә торган эш турында.

25. Казан шәһәрендә 1 нче күппрофильле балалар хастаханәсенең яңа бинасын төзү перспективалары хакында.

26. Халыкка диспансеризация үткәрү сыйфатын арттыру чаралары турында.

27. Онкологик авырулардан интегүче гражданнарны республиканың шифаханә-курорт учреждениеләрендә дәвалап бетерүне (реабилитацияләүне) оештыру хакында.

*Мәгариф, мәдәният*

28. Татарстан Республикасында китапханә системасын үстерү турында.

29. Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру хакында.

30. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру мәсьәләсен хәл итү перспективалары турында (шул исәптән спорт заллары төзү, иске биналарда урнашкан шәһәр мәктәпләренең спорт залларына капиталь ремонт үткәрү хакында).

31. Балалар-яшьләр спорт мәктәпләренең тренер-укытучыларына комплекслы ярдәм чаралары системасын оештыру турында.

32. Татарстан Республикасында яшь галимнәргә дәүләт ярдәме чараларын оештыру хакында.

33. Казан шәһәрендә Абдулла Алиш исемендәге Балалар иҗаты сараена капиталь ремонт үткәрү перспективалары турында.

*Җәмәгать иминлеге*

34. Миграция сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар хакында.

35. Гражданнарны, шулай ук аларның берләшмәләрен җәмәгать тәртибен саклауга җәлеп итү буенча Татарстан Республикасында, аерым алганда, Казан шәһәрендә күрелә торган чаралар турында.

36. Юлларда юл-транспорт һәлакәтләре һәм аларда һәлак булучылар санын киметү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар хакында.

37. Торак йортларда һәм гражданнар күпләп була торган урыннарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.

38. Мәгариф учреждениеләрендә балаларның иминлеген тәэмин итү һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозулар санын киметү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар хакында.

39. Гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта халыкны яклауга юнәлдерелгән чаралар турында. Халыкка хәбәр итүнең локаль системаларын торгызуга юнәлдерелгән чаралар хакында.

40. Өй эчләренә һәм фатирга куелган газ җайланмаларыннан файдаланганда һәм аларны карап тотканда куркынычсызлык тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелә торган чаралар турында.

41. Азык-төлек иминлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар хакында.

42. Татарстан Республикасында балаларның һәм яшүсмерләрнең деструктив тотышларын профилактикалауны оештыру турында, балигъ булмаган хокук бозучыларны реабилитацияләү һәм социальләштерү хакында.

*Экология*

43. Туфракны саклау һәм җир ресурсларыннан рациональ файдалану өлкәсендә законнарны үтәүгә, шул исәптән эрозия процессларын киметүгә юнәлдерелгән чаралар турында.

44. Атмосфера һавасы сыйфатын яхшыртуга һәм аның кеше сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмый калуга юнәлдерелгән чаралар хакында.

45. Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүнең торышы һәм аны үстерү перспективалары турында.

*Җирле үзидарә мәсьәләләре*

46. 2023 елда гражданнарның ихтыярый салым салу программасын гамәлгә ашыру һәм 2024 елда инициатив проектларны гамәлгә ашыру перспективалары хакында.

47. Җирле үзидарә органнарының җирле әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен, шулай ук җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү турында.